Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 октябрь 2019 ел №333

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 21 маендагы «Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премияне бирү Нигезләмәсе турында»гы 324 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премия бирү комиссиясе эшчәнлеген оештыру максатларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 21 маендагы «Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премияне бирү нигезләмәсе турында»гы 324 нче номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 30 маендагы 199 нчы номерлы, 2013 елның 7 февралендәге 820 нче номерлы, 2013 елның 19 апрелендәге 301 нче номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 69 нчы номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 307 нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кararга 1 нче кушымтада:

1.1.1. «Материалларны рәсмиләштерүгә таләпләр» 5 бүлегендәге 8 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Документлар тышлыгында «Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премияне алу өчен» дип күрсәтелгән папкага рәсмиләштерелә һәм комиссиягә түбәндәге адрес буенча җибәрелә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, 423450, Әлмәт шәһәре, Нефтьчеләр ур., 8 нче йорт, белешмәләр өчен телефон 8(8553) 22-14-99, факс 8(8553) 22-15-00.»;

1.1.2.«Комиссия вәкаләтләре» 6 бүлегендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Комиссия 12 кешедән тора, аның составы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары белән раслана»;

1.3. «Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге премияне бирү комиссиясе составы» турындагы карарның 2 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Әфләтүнова Роза Егоровна | - | Әлмәт муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| 2. | Лаптева Светлана Владимировна | - | район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. | Пайдуллина Гүзәл Атлас кызы | - | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының мәдәният идарәсе җитәкчесе, комиссия секретаре; |

комиссия әгъзалары:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Әл-Әйюби<br>Наилә Әгъләм кызы | - | Татарстан Республикасы Журналистлар берлегенең Әлмәт бүлекчәсе рәисе (килешү буенча); |
| 5. | Гыйззәтуллина<br>Гөлназ Әгъзаметдин кызы | | «Әлмәт таңнары» газетасы баш мөхәррире (килешү буенча); |
| 6. | Зарипова Ландыш<br>Нәгыймулла кызы | | Бөтендөнья татар конгрессының Әлмәт бүлеге җитәкчесе, “Альметьевский вестник” газетасы баш мөхәррире |
| 7. | Исмәгыйлева<br>Фәридә Бәгыйс кызы | | «Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе директоры (килешү буенча); |
| 8. | Нәҗметдинова<br>Рушания Нәзгат кызы | | «ТИСБИ» Идарә университетының Әлмәт филиалы директоры, Әлмәт муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча); |
| 9. | Сабирҗанова<br>Нәфисә Мөхәммәтгали кызы | | «Әлмәт» милли-мәдәни үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы менеджеры; |
| ).10. | Старшинина Лидия<br>Рахимовна | | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннар Советының мәдәният буенча комиссия рәисе |
| 11. | Шәйхетдинова<br>Флюра Әбелмәгъдән кызы | - | «Татнефть» хәйрия фондының «Рухият» программасы җитәкчесе (килешү буенча). |
| 12. | Шаһиев<br>Рәфкать Шириаздан улы | | Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Әлмәт бүлекчәсе рәисе (килешү буенча). |

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Салахов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов